РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘР
СОВЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 26 августы № 31

Түбән Кама шәһәренең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре Уставының 6 статьясы нигезендә, күчемсез милек хокукына ия булган затларның һәм күчемсез милек объектларына ия булу, алардан файдалану, эш итү хокукларын алырга теләгән затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү максатларында, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2010 елның 22 декабрендәге 20 номерлы карары белән расланган Түбән Кама шәһәренең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. әлеге карарга кушымта нигезендә, Түбән Кама шәһәренең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең картографик материалларына;

1.2. Түбән Кама шәһәренең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең текстлы материалларына:

25 статьяда:

Ж-3 территориаль зонасын рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләре исемлегендә «5-9 катлы күпфатирлы торак йортлар» сүзләрен «бизнес, сәүдә һәм башка хезмәт күрсәтү төрләре белән шөгыльләнү өчен, беренче каттан (яки беренче ике каттан) файдаланып, 5-9 катлы күпфатирлы торак йортлар» сүзләренә алмаштырырга;

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәр Советының шәһәр инфраструктурасын үстерү буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры
вазыйфаларын башкаручы,
Мэр урынбасары М.В. Камелина

Түбән Кама шәһәр Советының
2022 елның 26 августындагы
31 номерлы карарына
кушымта

Түбән Кама шәһәренең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең картографик материалларына кертелә торган үзгәрешләр

| т/с | Җир кишәрлекләре, К№ | Үзгәрешкә кадәр территориаль зона | Үзгәрештән соң территориаль зона | Планлаштырыла торган чара |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 16:53:040507:135, 16:53:040507:136 | ПК-3 IV-V куркынычлык классы җитештерү-коммуналь объектлар зонасы | Д-1 Эшлекле, иҗтимагый һәм коммерция билгеләнешендәге зона | Конфессиональ объектлар (мәчет) урнаштыру |
| 2 | 16:53:040309 | ИТ-4 Транспорт инфраструктурасы объектлары зонасы | Д-1 Эшлекле, иҗтимагый һәм коммерция билгеләнешендәге зона | Конфессиональ объектлар (чиркәү) урнаштыру |
| 3 | 16:53:040104:6582 | Д-4 Эшлекле үзәк зонасы, Ж-4 Югарырак күпкатлы торак йортлар төзү зонасы | Д-4 Эшлекле үзәк зонасы | Күпфатирлы торак йорт төзелеше |
| 4 | 16:53:040503 | Р-1 Рекреацион-ландшафт территорияләре зонасы | Д-1 Эшлекле, иҗтимагый һәм коммерция билгеләнешендәге зона | Күпфатирлы торак йорт төзелеше |
| 5 | 16:53:040101:0058 | ИТ-4 Транспорт инфраструктурасы объектлары зонасы | Д-1 Эшлекле, иҗтимагый һәм коммерция билгеләнешендәге зона | Сәүдә һәм хезмәт күрсәтү өлкәсе объекты |
| 6 | 16:53:040203:3766 | Ж-4 Югарырак күпкатлы торак йортлар төзү зонасы | Д-1 Эшлекле, иҗтимагый һәм коммерция билгеләнешендәге зона | Күпфатирлы торак йорт төзелеше |
| 7 | 16:53:040301:107 | Ж-3 5-8 катлы урта катлы торак йортлар төзү зонасы | Ж-4 Югарырак күпкатлы торак йортлар төзү зонасы | биек күпфатирлы торак йортлар төзелеше |
| 8 | 16:53:040503:160 | Ж-3 5-8 катлы урта катлы торак йортлар төзү зонасы | Д-1 Эшлекле, иҗтимагый һәм коммерция билгеләнешендәге зона | биек күпфатирлы торак йортлар төзелеше |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 9 | 16:53:030107:360 | ПК-1 I-II куркынычлык класслы җитештерү-коммуналь объектлар зонасы | ИТ-4 Транспорт инфраструктурасы объектлары зонасы | шин үзәге (машина кую урыны) |
| 10 | 16:53:040304:460, 16:53:040304:461, 16:53:040304:462 | Д-4 Эшлекле үзәк зонасы, Ж-4 Югарырак күпкатлы торак йортлар төзү зонасы | Д-1 Эшлекле, иҗтимагый һәм коммерция билгеләнешендәге зона | мәдәни үзәк |
| 11 | 16:53:040101 | Ж-2 Азкатлы торак йортлар төзү зонасы | Ж-3 5-8 катлы урта катлы торак йортлар төзү зонасы | урта катлы торак төзелеше |

Түбән Кама шәһәре
Мэры урынбасары М.В. Камелина

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ * РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ ГОРОД НИЖНЕКАМСК
ПРЕДСТАВИТЕЛЬНЫЙ ОРГАН
ВӘКИЛЛЕКЛЕ ОРГАН